Это мать моя бедная в старости тяжкой.

Другим мне этого не объяснить,
Но я не могу ее не любить.

В глазах ее нет занебесного света,
Из уст не услышишь ни слова привета,
В объятьях нет страсти, зовущей к безумствам.
В постели она – не тигрица, не дьявол,
Не умеет дерзить, спокойная нравом,
Сильна лишь в возиться с посудой искусстве,
Это женка моя, неказистая с виду.

Другим мне этого не объяснить,
Но я не могу ее не любить.

Всегда пребывающий в полудремоте,

Всегда в малахае, что скроет зевоту,

Избравший лишь лень себе вечной опорой.

По старым заветам все также живущий,

С отарой встающий, с отарой бредущий,

Есть народ мой «алаш» на движенье нескорый.

Другим мне этого не объяснить,

Но я не могу его не любить.

Миражной завесою вечно покрытый,

В буранах взвывающих грозно, сердито,

С зимою как саван и с летом свирепым.

Не имеющий леса, не имеющий рощи,

Не имеющий гор, где вода в речках ропщет,

А имеющий только лишь мертвые степи,

Это вот Сарарка – моя родина в дреме,

Другим мне этого не объяснить,

Но я не могу ее не любить.

## ЗАГАДКА

Перевод Ауэзхана Кодара

Дол золотой
Ветра игрой
В гул растворен.
Слышится гул,
Едет аул
Ветру вдогон.

Степь вечно спит,
Мальчик молчит.
Две немоты.
Тайна в них – та,
Что немота
Суть маеты.

Дол золотой
Ветра игрой
В гул растворен.
Мальчик и степь...
Кто из них слеп?
Кто из них - сон?

## НЕМНОГО ПО ФЕТУ

Перевод Ауэзхана Кодара

Ночи шелк,
Ветер смолк.
Он, она.
Тишина.
Они - вон,
Смеха звон.
Так пьяны,
Влюблены.
Месяц тих
У реки.
Соловей,
Ветер вей.
Остуди,
Пыл в груди.
«Ах, не тронь!»
Губ огонь.
Тихий бор,
Разговор.
Сопок ряд,
Жаркий взгляд.
Шепоток,
Чувств поток.
Туч моря,
И – заря.

## МЕНЯ ТОЖЕ, О, СМЕРТЬ, УПОКОЙ!

Перевод Ауэзхана Кодара

Нет сил моих больше, устал я вконец,
Клубятся и тучи, что цветом в свинец,
И ветер лениво нам взвоет о том,
Что кто-то вот умер: как жизнь коротка,
Мы также все бренны как те облака...
О, ветер, не надо жалеть ни о ком.
Прошу, успокойся, и плач свой уйми,
Ведь смерть – это радость, ты этой пойми.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Одна на опушке, дрожа на ветру,
Росла молодая березка в бору.
Ее донимал только ветра напор.
Вся в листьях как в серьгах, звеня, шелестя,
Пленяла собою она как дитя.
Так что опечалить могло ее взор?
Упала березка однажды вповал,
Один только ветер над нею рыдал.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Подняв над собою трепещущий флаг,
С клинком, от которого в ужасе враг,
Напором, подобный разливу реки,
Юнец черноглазый, насуплен и хмур,
С врагами сражался, чтоб выбить в них дурь,
И в битве со звоном встречались клинки.
Погиб тот юнец, хоть возрастом мал,
Над ним только ветер молитву читал.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!



Убогая степь, всюду пустошь одна,
В убогой степи только тропка видна.
Там путник идет по тропе, одинок.
Идет день и ночь, ему важно дойти,
Вся обувь истлела на этом пути.
И вот, наконец, заалел вдруг восток.
Но путник наш умер, хоть близок был дом,
Занес его ветер прохладным песком.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

…румянцем на щечках, что очень к лицу,
…ивою речью ласкающей слух,
С кудрями, что вьются лозой смоляной.
…смех ее звонкий, как жемчуг вразброс,
…а как цветочек, что только пророс,
Пятнадцать ей лет стало этой весной.
…на в тишине пролила столько слез,
…ти ей из жизни в печали пришлось.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Ребенок лопочущий, ангел земной,
Он всех рассмешит, такой милый, смешной.
О чем-то толкует, что нам невдомек.
Он крохотней ягод, нежней тростника,
О горечи жизни не знает пока.
Источник надежды, любви родничок.
Но сглазили, видно, не стало мальца,
Лишь ветер тоскует о нем без конца.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Волнуется озеро в дальней дали,
Жемчужные волны накатом пошли.
На дне этих волн, не поймешь толком где,

Воздвигнуты юрты – числом шестьдесят,
Завесы из шелка сверкают, блестят.
А там, за завесой, в прозрачной воде,
Волнистые волосы в юртах видны,
С нагими телами повсюду они.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Отрада для глаз, удалой мальчуган,
Любовью родительской он осиян.
Спустился наш мальчик на самое дно.
Пошел он по юртам, к красавицам тем,
Он их обнимал... да и умер затем.
И ветер об этом от волн лишь узнал,
А скорбь поглотила бескрайняя даль.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Идя с мальчуганом сквозь чистый поток,
Возьму я красавицу под локоток.
С юнцом удалым навсегда подружусь.
Сквозь волны шагая с березкой младой,
Мальца приласкаю с отцовской тоской,
И с путником я разделю его грусть.
Пусть тоже умру я скорей как они,

Не стану жалеть свои юные дни.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

Возьми на колени меня как мальца,
Целуй меня сладко, целуй без конца.
Приди же, о, смерть, прошу, поскорей.
Вот замерло сердце, лежу не дыша,
Взлетать перестала бунтарка-душа,
А некогда не было духа бодрей.
Возьми на колени меня и целуй,
Баюкая волнами, шепотом струй.
Душа моя млеет от блажи такой!
Меня тоже, о, смерть, упокой!
Упокой меня, смерть, упокой!

## ВОЛНА

Перевод Ауэзхана Кодара

Из волны родится волна,
Догоняет подружку она,
Друг за дружкой вдогонку бегут.
И, как будто, тоскуя о ком,
В нескончаемом споре лихом,
До утеса в раздоре их путь.

Там волна поверяет волне
Свои тайны, что были на дне
Их ранимых и нежных сердец.
Жемчуг пены блестит как венок,
Извиваясь в воде как вьюнок,
До утеса дойдут, наконец!

Детским лепетом дивным журча,
Серебром став в потоке ключа,
Ударяются выдохнув «Цок!»
Серебром, что по вкусу как мед,
Золотым истечением вод,
Омывают утесу лицо.

Ожемчужены каплями слез,
Омывая слезами утес,
Засмеются, целуя его.

Этот смех их веселый есть плач,
Он – предвестье больших неудач,
 Смех и плач – это смерть ведь всего.

Порождая трезвон золотой,
Одну тайну крадя за другой,
 Серебрится волна за волной.
Мед отдавши, тому, кто им мил,
Умирают без страсти и сил,
 На дне моря находят покой.

## ВЕТЕР

Перевод Ауэзхана Кодара

Вон ветер – мальчик озорной,
Степь любит пламенной душой.
Ему покой неведом.
Губами будто шевеля,
Зашепчет из-под ковыля,
Или, завоет следом.

Нет ветру равных тут и там,
Вот он забегал по горам,
Смеясь, он брал преграды.
Не прячьтесь, все равно найдет,
Плевком в лицо вам попадет,
И убежит, неладен.

Он беспокойный баламут,
Пораньше встанет он и в путь.
И ну, ползти по полю.
Пристанет к озеру, что спит,
Ее измучит, изрябит,
С ней поиграет вволю.

Потом разбудит древний бор,
Утешит чем-то, резв и скор,

Приветит старца, ласков.
И умеряя свою прыть,
Стараясь чувства свои скрыть,
Заглянет к черноглазке.

Дыша в лицо ей горячо,
Схватив легонько за плечо,
Он скажет, скорбен слишком.
«Я прилетел к тебе с зарей,
Дай поцелуй мне, ангел мой,
Приветь меня, глупышку!»

Она молчит, а он взахлеб,
В глаза целует, в губы, в лоб,
То в грудь запустит руку.
Я рад, красотка, за тебя,
Ах, почему не ветер я,
Все остальное – скука!

## СВОБОДА

Перевод Ауэзха

Когда землю покрыл всю кровавый потоп,
Когда пена взлетала до неба взахлеб,
Когда бес человека попутал, и, он
Позабыл для чего ему разум был дан,
Когда Библию рвали, топтали Коран,
Когда равенства, братства был попран закон.

Когда люди ходили по локоть в крови,
Когда сердце застыло забыв о любви,
Был в почете предатель, почитаем был лгун.
Когда резали все, всех косили подряд,
И верблюдицу дойную, мать верблюжат,
Когда Тенгри исчез, превратившись в таньгу.

Когда только шайтан правил миром, жесток,
Когда всюду вражда нам затмила исток,
И казалось, что все: жизнь в добре лишь мечта.
Отворились врата и с высоких небес,
В райском свете похожа на райскую весть,
Прилетела Свобода как ангел чиста;

Ее лик ослеплял словно солнечный смерч,
Была словно из шелка волшебная речь,
И белели, лучась, два алмазных крыла.

Все живое вокруг, чтоб увидеть живьем,
В удивленьи большом окружило ее,
А она, улыбаясь, им рада была.

Осиянные светом, почтенья полны,
Затаивши дыханье, стояли они.
И, казалось, что счастью не будет конца.
Те, кто света не видел, был жертвой невзгод,
Неодетый, голодный и бедный народ,
Для веселья открыли умы и сердца.

Загорается быстро и гаснет легко,
Человек на решенья глупые скор,
Не за это ль был изгнан из рая Творцом?
Вот пришел он в себя, вновь достаток обрел,
И так к свету привык, так вошел в эту роль,
Что за старое взялся к стяжанью влеком.

Снова побоку честь, нагулял аппетит,
Божий суд и людской вновь его не страшит,
Про свободу забыл, что так тяжко далась.
Снова топчет других: всюду плач или вой,
Снова всюду резня, кровь повсюду – рекой,
Снова ложь и грабеж, вновь убийства и грязь.

Вновь подонки в ходу, коих выгнали вон,
Чьи сердца словно гниль, источают лишь вонь.

Вот кто ныне достиг своей цели опять.
Жуткой массой ползут тараканы, жучки,
Снова хрюк издают кабанов пятачки,
Снова гостью с небес они жаждут изгнать.

И ругают ее, и зовут сатаной,
И идут на нее дружной в злобе стеной,
Вновь повсюду вражда восстает из золы.
У посланницы рая поблек ореол,
Над священною гостьей – толпы произвол,
В пятнах грязи и крылья, что были белы.



Жуткой массой ползут тараканы, жучки,
Снова хрюк издают кабанов пятачки,
Торжествуют, смеются: сбылась их мечта.
А свобода, расправив два белых крыла,
Приготовилась взмыть в край, не знающий зла,
Как и прежде, невинна, как и прежде, чиста.

Пусть землю покроет потоп мировой!
Пусть скроются горы под шалой водой!
И брызгая пеной, как ядом морским,
Воздымутся волны, гора за горой.

Пусть землю покроет потоп не щадя!
Пусть пена сокроет глаз солнца, гудя!
Где трепета жизни не видно ни в чем,
Пусть в мире пустынном останусь лишь я!

Пусть сгинет живое не в силах вздохнуть!
Безмолвья настанет предельного жуть!
Над мраком земли, где не видно не зги,
Мне Солнцем взойти бы ярчайшим, как суть!

О, как я понесся б над сирой землей!
Очистил бы пламенем всё под собой!
И в мире бескрайнем – без дна и вершин,
Остался б один я, как шар огневой!

Как молния скор и как бог, одинок,
Без тех, кто душою давно уж иссох,
Я создал бы, верьте мне, новых людей,
Я их из огня своего бы исторг!

## АЛЕКСАНДР БЛОК

Перевод Ауэзхана Кодара

Александр Блок,
Сердцем как уголек,
В надежду лишь верил одну.
Погружаясь в печаль,
Он все Даму искал,
Терзая ночами луну.

Он искал ее днем,
Ночью – чуть не с огнем,
Покоя и сна он не знал.
Александр Блок,
Сердцем как уголек,
Пытал молчаливую даль.

Звал ее – «Идеал»,
В грезах к ней лишь взмывал,
Был Блок заморочен, ей-ей!
Если Дама – цветок,
Соловьем ей был Блок,
Без устали пел соловей.

Заливался все Блок,
Пел ей гимн свой, как мог.
Вплетал и страданье и свет.

Вот и жизнь уж прошла,

Плохи Блока дела,

    От Дамы известий все нет.

Дни за днями бегут,

Ночи молча текут,

    Закончился сладостный гимн.

Болен, сир, одинок,

Что же видит наш Блок?

    Старуха стоит перед ним.

Вот тебе идеал,

Вот что ты все искал,

    Развеялось это все в дым.

Сердце как уголек,

Только плачет наш Блок,

    Он понял, что был нелюбим.

Идеала-та нет,

А старуха есть смерть,

    Как смотрит, карга, из-под век?!

Жизни свет в нем угас,

Гимн заглох в тот же час,

    Только «Дама» осталась навек.

## ПЕЧАЛЬНАЯ БЕРЕЗКА

Перевод Ауэзхана К[illegible]

Печальная березка,
Тебе зимой непросто.
Под ветром наклоняясь,
Забыла ты про тишь.
О чем-то шепчешь, шепчешь,
И вся дрожишь, дрожишь.
А ветер зол и гневен,
В порывах очень жестких.
И, будто ветра мало,
Ты терпишь снег устало.
Покрыл тебя он густо,
Как саван, бел и сух.
И так тебя сжимает,
Что вынимает дух.
Придет ли лето, о, березка,
Когда воды напившись чистой,
Распустишь пышно свои листья?
Когда качая твои ветви,

Завеет нежно ветер летний?
Когда задремлешь потихоньку
От птичьих песен очень звонких?
Но ныне ты грустна, угрюма,
Так и застыла в тяжких думах.
Ушла ты вся в мечты о лете,
Тебя буран плевками метит.
Я одного тебя желаю –
Пусть Бог твою печаль заметит.

## МОТЫЛЕК

Перевод Ауэзхана [illegible]

Летит на огонь мотылек,
Без оглядки, бедняга, летит.
Ему в тот момент невдомек,
Что сгинет в огне он, сгорит.

Кругами кружа иль мечась,
Он сядет, чтоб снова вспарить.
Но пламя, взметнувшись, тотчас
Его опалит и спалит.

Друзья, делу спешка вредит,
Завет бы запомнить простой.
Не золото все, что блестит,
За всей не угнаться красой.

Нелепо вслед ветру лететь,
Постигнет судьба мотылька.
За золотом ждет только смерть
В плаще из золы и песка.

## ТЕМНАЯ, БУРАННАЯ НОЧЬ

Перевод Ауэзхана Кодара

В бескрайней степи – буранная ночь,
Повсюду – лишь смерти унылое царство.
Я факел зажег, чтобы свету помочь
Усилить покрытое мраком пространство.

Пусть черные тучи нависли с небес,
Пусть вьюга ярится, вздымая метели,
Но в слабых руках слабый свет не исчез,
Он виден в ночи, хоть и теплится еле.

Пусть светом таким и нельзя удивить,
Надеюсь, он выдержит долгие годы.
Я с Солнцем, Луной мог его бы сравнить,
Без коих во мгле бы осталась природа.

Возможно, его гордецы не поймут,
Обидят насмешкой живущие прахом,
Не стану на это смущаться ничуть,
Уверен есть те, кто поддержит мой факел.

## ВСЕ ГУЩЕ МРАК НОЧНОЙ

Перевод Ауэзхана Кодара

Все гуще, гуще мрак ночной,
В печи уж уголь стал золой.
Раздуть пытаясь уголек,
Смеется мальчик, что со мной.

Вот искра вспыхнула в свой срок,
Вот показался огонек.
Но разгореться не успев,
Погас он сразу, одинок.

Тихонько гаснет угль в печи,
Смеется мальчуган в ночи.
Слезами полнится мой взгляд,
А тьма таится и молчит

## СТАЛ ГУЩЕ ТЕМНЫЙ ЛЕС

Перевод Ауэзхана Кодара

Стал гуще темный лес
Из сосен и берез.
Друг вечных он небес,
Молчащий в полный рост.

Завернут в саван, скрыт,
Спит старец, как дитя.
Буран, вопя, скорбит,
Молитвой старца чтя.

Немотствует старик
И спит неколебим.
А я взгрустнул на миг
И грежу вместе с ним.

Заснуть как он без мук,
Забыть про грусть-печаль.
Чтоб ветер выл вокруг,
Меня бы отпевал.

## ПАПИРОСА

Перевод Ауэзхана [illegible]

В руке – папироса,
Стряхаю вопросы
Вместе с пеплом в горшочек, что пус
Забывшись порою,
Я в дым весь зароюсь,
И дымом, что густ, захлебнусь.

Жизнь – речки быстринка,
Надежда – тростинка,
Я поплавать в быстринке решусь.
Но только я – в воду,
Хоть мелко здесь вроде,
Неожиданно я захлебнусь.

Забывшись порою,
Я в дым весь зароюсь,
Буду кашлять от дыма, что густ.
Жизнь – хрупкость тростинки,
Надежда, как льдинка,
Яд приму и умру, задохнусь.

## МЫСЛЬ

Перевод Ауэзхана Кодара



Мысль – это яд,
Так утоляет жажду.
Мысль – это яд,
А яд снесет не каждый.
Мысль – это яд,
В нем столько опьяненья,
Мысль – это яд,
Готовься к омертвенью.

Подобна морю мысль,
Валы натужно гонит.
Подобна морю мысль,
Волнуется до стона.
Подобна морю мысль,
Без края, дна теченье.
Подобна морю мысль,
Цена лишь жизнь влеченью.

Отравлен мыслью я,

Теряю, значит, разум,
Отравлен мыслью я,
Знать, в сердце есть зараза.
Отравлен мыслью я,
Горю я чисто, ясно.
Отравлен мыслью я,
Увяну и погасну.

# СОН

Перевод Ауэзхана Кодара

Мой взор не видит ни луны, ни солнца,
Свет дня давно погас в моем оконце.
Я не пойму, чему так рады люди,
Лишь жду тот миг, когда свой срок закончу.

Я полон сил напрасных и нелепых,
В тюрьме зачем мне эти мощь и трепет?
Я сна лишь жажду, словно утешенья,
И то смыкаться не желают веки.

## ОДА ГЛАГОЛЬНОЙ РИФМЕ

Перевод Ауэзхана Кодара

Бедняга квёлый – «пропустил»,
В раздумьях что-то – «отпустил»,
Отраву пил – «не запустил»,
В кустах играя – «не грустил».
Надежду вечно он – «растил»,
Был одинок, но всех «простил».
Что за стихи с концом на «сти»?
К чертям! Пойду овец пасти!

## ДРУЖБА И СЛЕЗЫ

Перевод Ауэзхана Кодара



Рождает дружбу пьянства транс,
Два пьяных – это дружбы шанс.
Как выпьешь, сердцу горячо,
И слезы льются в дилижанс.

Болезнь рождает дружбы цвет,
Больного лучше друга нет.
Жалея, плачем вслед ему,
И слёзы капают в кювет.

А тот, кто трезва, тот зверь лесной,
Здоровый – это не больной.
И трезвый дружбу не поймет,
Он слезы лить не станет, злой.

## ПОЭТУ-СОВРЕМЕННИКУ

Перевод Ауэзхана Кода[illegible]

Смотрю в окно и вижу Вас,
Лижу потом я карандаш.
Размеры, строки подсчитав,
Иду спокойно я на марш.

На стих нацелен я всегда,
Не дописать стихи – беда!
Не знают люди, Бог простит,
Краду у Фета без стыда.

## О, ГОСПОДИН НАШ, ГОСПОДИН

Перевод Ауэзхана Кодара

О, господин наш, господин!
По дому видно, важный чин
Тут проживает... Знатный дом!
Какая роскошь! Блеск один!
Берете, видно, Вы с людей,
Охоч давать простолюдин.
Не перейду я к Вам на ты,
Скажу как чёрту только: «Сгинь!»

## НЕДУГ

Перевод Ауэзхана Ко[illegible]

Врачам ли это вызнать,
Шаман тут слаб, поверьте.
Мне смерть дороже жизни,
Я сам прошу о смерти.

Шаман и доктор нужен,
В болезни человеку.
Когда душа недужит,
Найдется ли ей лекарь?

Телесной боли можем
Помочь, - прервать мученье.
Так отчего, о, боже,
Душе нет излеченья?

## ЗВЕЗДАМ

Перевод Ауэзхана Кодара

Так много вас, глаза небес,
Не стройте с неба глазки.
Я не смогу быть в гости к вам,
Эй, туча, скрой их сказку!

Бедняга я, что обречен
Рабом земли быть вечно.
Туда-сюда меня ведя,
Мной ветер правит желчно.

Покорен я, и, всё ж, Аллах,
Я нахожусь в смятеньи.
Мой дух так тонок, так пытлив,
На что душе горенье?

Раз создал ты меня рабом,
Дай духу кротость, робость.
Но всё не так... О небеса,
Откуда же я родом?

## ЧАСЫ

Перевод Ауэзхана Кодара

Часам покоя нет,
Стучат они: «Вон-вон!»
Пришли мы в белый свет
Небытию в догон.

В обмане порожден,
Рад жизни человек.
Но вот прозреет он,
И жизнь чужда навек.

С порога уж кричат
Ему «вон-вон!» уйти.
Жизнь – череда утрат
Без счастья на пути.

Пришел и твой черёд,
Часов суров приказ.
«Вон-вон!», иди вперёд,
Настал твой смертный час.

## ПОГОНЯЙ ЖЕ КОНЯ, САРСЕМБАЙ!

Перевод Ауэзхана Кодара

Погоняй же коня, Сарсембай!
Мы поедем в родимый мой край!
До зари мы уедем с тобой.
Погоняй же, скорее, коня,
Эх, достала учеба меня,
А так в город бы я – ни ногой!

Оглянись, у тебя позади
Он разлегся как сумрачный див,
Это город – громада громад.
Он таится в тумане ночном,
Дышит дымом, угаром, огнем;
Его очи недобро блестят.

Столько шума в нем, гама, возни,
Столько всякой дурной болтовни,
Столько вони, что крикнешь «Ойбай!»
Так чего озираться назад,
Нам в аул бы скорее, мой брат,
Погоняй же коня, Сарсембай!

Женщин их ты ничем не проймешь,
Обожают измену и ложь,
Строят глазки на каждом шагу.
Бледнолицы как немочи взвар,

С тусклым взглядом, забывшим про жар
Их мужчины – на радость врагу.

Не найти в них горячих сердец,
Идеал их: скорее поесть, -
Кабаны, секачи-хрюкачи.
Дети ночи, им ночь лишь приют,
Лишь в вонючих коробках живут,
И общаются только в ночи.

Небесами ты их не возмешь,
Посмотри, сколько радостных звезд!
Вон Луна улыбается: «Ай».
Во мне город рождает лишь боль,
Быть в разлуке со степью доколь?
Погоняй же коня, Сарсембай!

Потянуло, что ли, ко сну?
Сарсембай, спой хоть песню одну,
Ту, которая нас встрепенет!
Скоро буду в родном я краю,
Где любивших меня я люблю,
Сердце, ну же, отправься в полет!

Сарарка, ты же – светочь души,
Ты – моя бескрайняя ширь,
Я всей грудью к тебе припаду.

Ветерок твой обнимет как шелк,
Будет дорог мне каждый глоток
Из ключа, что течет на меду.

Не хочу озираться назад,
Мы вдали ли от города, брат?
Успокой же меня, дух придай!
Нам нельзя озираться назад,
Нам в аул бы скорее, мой брат,
Погоняй же коня, Сарсембай!

## КАЗАХСКИЙ ЯЗЫК

Перевод Ауэз[illegible]

*Нет сил уже больше, повержено знамя побед,*
Герои поникли от тысяч напастей и бед.
Их гордые души страдают теперь в кандалах,
Нет жара в крови и сердцу, как прежде, не петь!

Какая досада – подрезаны крылья орла!
Могучий народ низведен к положенью вола.
Не помним теперь мы и родину предков – Алтай,
Батыров и ханов забыты святые дела!

Нет больше героев, страна коченеет в беде.
Не встретить теперь единенья и чести нигде.
О, предков язык, словно тень ты тех солнечных дней,
Тебе поклоняюсь я, как негасимой звезде!

Пускай ты в подполье, в себе ты богатство таишь!
Ты – чистый, глубокий, раздольный и мощный как клич!
Я верю – однажды разбредшихся, сирых детей,
Позвав словно мать, ты в объятья свои заключишь!

# КРАСНОЕ ЗНАМЯ

Перевод Ауэзхана Кодара

Чье это знамя горит, пламенея?
О, Азия – житель отрогов и скал,
По-прежнему грозен врагу твой оскал.
Того это знамя, кто биться умеет.
Кто счастье в борьбе лишь найдет.
Знать, казах, это знамя – твое!

Чье это знамя горит, опаляя?
Того, кто огонь почитает Творцом,
Того, для кого он давно стал отцом!
Того, кто дороже святыни не знает!
Кто счастье в борьбе лишь найдет.
Знать, казах, это знамя – твое!

Чье это знамя горит, полыхая?
Того, кто в степи обескровлен вконец,
Кто к мести готовит свой меч-кладенец,
Того, кто покоя в походах не знает.
Кто счастье в борьбе лишь найдет.
Знать, казах, это знамя – твое!

Чье знамя в кровавых слезах сатанеет?
Того, чьи сыны превратились в рабов,
Того, в чьих мужчинах выдохлась кровь,
Того, кто не плакать уже не умеет.
Кто счастье в борьбе лишь найдет.
Знать, казах, это знамя – твое!

Чье это знамя горит, не сгорая?
Того, кто обижен сгорел раньше срока,
Того, кто обобран, страдает жестоко.
Того, кто от бедствий несчетных стенает.
Кто счастье в борьбе лишь найдет.
Знать, казах, это знамя – твое!

Чье знамя свободы, как сердце, трепещет?
Того, кто не равен в богатстве со всеми,
Того, кто растоптан, унижен все время,
Того, чей удел не становится легче.
Кто счастье в борьбе лишь найдет.
Знать, казах, это знамя – твое!

# Mağcan Cumabay

# Tatar Türkçesi ile Şiirler
# Татар тіліндегі өлеңдер

## Җил

Тәрҗемәче Нури Арсланов

Җил бик шаян бер бала
Җан сөйгәне сардала,
Бер туктамый йөгерә.
Иреннәре елмая,
Сер әйткәндәй кылана,
Я ерткычтай үкерә.

Җилне беркем куалмый,
Тау да юлын буалмый,
Җил шаркылдый, сикерә.
Җил ашыга, җил чаба,
Берәү йөзен капласа,—
Ача, биткә төкерә.

Тынгысыз җил бик иркә,
Уяна да бик иртә,
Уйнаклап йөгереп китә.
Төш күреп яткан чакта
Күл битен шадралата,
Аны әүвәрә итә.

Карт урманны уятып,
Әллә ни дип юатып,
Елмаеп-көлеп үтә.

Күр бәхетле җил түен,—
Әйтергә серен-уен
Карлыган күзгә җитә.

Тын алалмый ашыгып,
Йотлыгып та, баш орып:
«Сиңа — сылу, бәгырьгә
Килдем очып, гашыйкмын!
Бер үбәргә ашыктым,
Кара миңа, фәкыйрьгә!»

Ди дә, үбеп күзеннән,
Чәче, алма йөзеннән,
Коча асыл иркәсен...
Бәхетле җил, назлы җан!
Ва дәрига, йә мәүлям,
Ник мине җил итмәдең?!

## Нәкъ шул сәгатьтә

Тәрҗемәче Нури Арсланов

Күрдем дә килдем,
Кулымны бирдем:
«Сөям сине, сылу кыз.
Йөрәгем — очкын,
Сөюләрем — чын,
Гуаһ булсын күп йолдыз»

Дип татлы телдән,
Кочаклап билдән,
Шашып үбә башладым.
Якынладың син,
Тартылмадың син,
Кит, димәдең, качмадың.

«Сөям!» дип үзең,
Мөлдерәп күзең.
Тидердең син биткә-бит.
Мондый язмыштан
Яздым мин һуштан,
Бәгърем, мине гафу ит!..

Бәйгегә комар,
Торамы толпар

Бер урында чаң йотып?
Җил идем, очтым,
Күпләрне кочтым,—
Киттем сине онытып.

Бүген син килеп,
Кулыңны биреп,
Кайгы белән карыйсың:
«Ышандым, яран,
Сөюең ялган,
Алдадың!» дип агълыйсың.

«Алдамадым мин,
Арбамадым мин,
Ышан сүзгә, сылу кыз,—
Нәкъ шул сәгатьтә
Сөйдем, әлбәттә!
Гуаһ моңа күп йолдыз».

## Төш

Тәрҗемәче Нури Арсланов

Яктылыкны — айны-көнне күрмимен,
Ярым үлек, тулы гомер сөрмимен...
Иректәге шат яшәгән халыкның
Нишләгәнен, ни дигәнен белмимен.

Хур иттем мин гайрәтне дә, көчне дә.
Кулдан килсен төрмәдә ни эш кенә?
Йокларга дип йомамын күзләремне,
Бер чара юк, юанычым төш кенә.

## Булса гөлсез

Тәрҗемәче Нури Арсланов

Булса гөлсез —
Былбыл өнсез,
Өнсез былбыл — соры кош.

Өнсез гомер —
Сүнгән күмер,
Утсыз йөрәк — буш куыш.

## Җир йөзен басса туфан

Тәрҗемәче Нури А[illegible]

Җир йөзен басса туфан,
Таулардан ашса туфан,
Кайнатып дулкыннарын
Күбекләр чәчсә туфан!
Юса туфан җир өстен,
Япса томан күк йөзен!
Җанлы-җансыз күмелеп,
Калсам җирдә бер үзем!
Җирдә өннәр тынсалар,
Җан иясе югалса,
Балкыр иде дөньялар,
Кояш булып мин янсам!
Ут — телем белән җирне
Бер ялап алсам иде,—
Яктыртып кара төнне
Бер үзем калсам иде!
Янгынымнан бу фәна
Көл булса яна-яна,
Гаҗәп кеше өр-яңа
Ясар идем дөньяга!

## Аксак Тимер сүзләре

Тәрҗемәче Нури Арсланов

— Җиһан диләр, нәрсә ул?
Тик бер уч төбе генә.
Димәк, булырга тиеш
Җирдә хуҗа бер генә!
Тәңре — күкнең тәңресе,
Мәгърур күген биләсен.

Җир тәңресе Тимер — мин,
Җиремә тәңре тимәсен.
Күк хуҗасы тәңренең
Нәселе юк, заты юк.
Җир тәңресе Тимернең
Нәселе төрек, заты ут!

## Күбәләк

Тәрҗемәче Нури Арслан



Утка оча күбәләк,
Алга-артка карамый:
Белми мескен, ул утны
Һәлакәткә санамый.

Ут тирәли әйләнеп
Йөрер дә ул бер кунар:
Кызыкканы байгошны
Көйдерер дә — җан тынар.

Дустым, син дә омтылсаң,
Уйламый какма канат,
«Һәр балкыган алтын» дип,
Чапма ялкынга карап.

Җилгә ачсак канатны,
Күбәләктәй көярбез,
«Алтынга!» дип барганда,
Көлдән кәфен киярбез.

## Ут

Тәрҗемәче Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

Көннән туган баламын,
Яндырамын, янамын,—
Көнгә генә багынам.
Үзем — көнмен, үзем — ут,
Сүзем, кысык күзем ут, —
Үз-үземә табынам.
Җирдә ялгыз тәңре — ут.
Уттан башка тәңре юк.

Ялкын йомшак сөядер,
Сөйгән җирең — көядер, —
Ялмап-сыйпап юмалар.
Очраганны ут кылыр,
Ут кабынып юк кылыр.
Аның аты — Ут булыр.
Мин дә утмын — кабынам.
Ут — син, Тәңрем,—табынам.

Адәм — күкнең ялкыны,
Кысыр сулыш аркылы
Ялкын йоткандай тоям.
Гаиләм, өем, котыма,
Тиңсез тәңрем-утыма
Вакыт-вакыт май коям.

Май коямын — ут лачын
Куккә җәя колачын...

Көйде елан чорналып,
Көйде аждаһа ялманып —
Яндың, чыгар кем синнән?
Чынында мин үзем — ут.
Кысык кара күзем — ут.
Мин уттанмын, ут миннән.
Яндырамын, янамын,
Уттан туган баламын.



Караңгылык батканда,
Кояшы калыкканда
Көн утыннан туганмын.
Йөрәгемне, җанымны,
Иманым, вөҗданымны
Ялкын белән юганмын.
Йөрәгем, җаным да — ут,
Иман, вөҗданым да — ут!

Ут яндырып туганга,
Бугазымнан буганга
Караңгылык — дошманым.
Шул явызны юк итсәм,
Сукыр күзен ут итсәм
Үтим Тәңре кушканың:

Алып чыккан Алтайдан
Балкайгача — Кытайдан —
Барган юлым шул булыр...

Көннән туган баламын,
Яндырамын, янамын.
Үзем—Кояш, Үзем—Ут.
Сүзем, кысык күзем—Ут.
Үз-үземә табынам.
Җирдә ялгыз Тәңре—ут.
Уттан башка Тәңре юк!

## Баланың кабер ташына

Тәрҗемәче Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

Кайгырмагыз бу сабыйны үлде, диеп,
Тач кызыл гөл мизгел җитми сулды, диеп.
Бәхете юк зарлы ата-ананың
Янар-янмас шәм-чырагы сүнде, диеп.

Ис китәрлек: җирне ташлап киткәненә —
Чын бәхеткә иртә барып җиткәненә,—
Изге өең—җайлы җәннәт түреннән
Урын алып, ата-анасын көткәненә.

## Пәйгамбәр

Тәрҗемәче Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

Устремляя наши очи
На бледнеющий Восток,
Дети скорби, дети ночи,
Ждем, не придет ли наш Пророк.

Д.С. МЕРЕЖКОВСКИЙ.

Көнбатышны караңгылык каплаган,
Кояшы батып, яңа таңы атмаган.
Көнне төнгә әйләндергән пәриләр
Үз тәңресен табан илә таптаган.

Көнбатышны караңгылык каплаган,
Ник бер йолдыз калсын күктә батмаган;
Төн баласы, үз изгесен үтереп,
Табанында изә-изә таптаган.

Көнбатышны караңгылык каплаган,
Бер җан да юк караңгыга эләкмәгән;
Белүче юк иман нәрсә икәнен,
«Корсак» дигән сүзне алар ятлаган.

Төн баласы... Төн юлына төшкән ул,
Син сакау, дип, Муса телен кискән ул,
Тәңресенең сөекле улы Гайсәнең
Тетрәнмичә уртлап канын эчкән ул.

Төн баласы төн киемен ябынган,
Аллага, юк, газазилгә табынган.
Инҗил ягып, алтынга башын иеп,
Гаделлек көтә корсактан-карыннан.

Төн баласы гомерең тәмам таң белән,
Кабил углы авызланган кан белән.
Табынырга эре җанвар күрдисә,
Саубуллашырга да әзер җан белән.

Юк, түгелми ярыннан ашса да су,
Юк, үтерми сөюдән ташкан агу,
Төн баласы, күтәреп түр өлгене,
Күзеңне сал – көнбатыш ул кан агу.

Күзгә төртсәң күренмәслек кара төн,
Иңрәүче кем, көлүче кем—әллә кем?
Алай итәр, болай итәр дә китәр,
Ул кем булыр? Төн баласы кара җен!

Кап-кара төн. Төн баласы иңридер.
Иңрәүченең берсе уннан бередер.
Сыгынды, сүрелде, тагын аһ итте,
Кара төндә тагын нәрсә күрердер.

Кап-кара төн. Шагыйрь күзе моңлана.
Кап-кара төн. Кайгы, кан уйнап ала.

Кайгы белән кара канга тончыгып
Төн баласы авыр уйлар уйлана.

Заманында утлы көннән һун* туган,
Утлы һуннан утта уйнап мин туган.
Йөземне һәм кысык кара күземне
Туганда ук ялкын белән мин юган.

Бик кайгырма, сукыр чор, дип, килде зар.
Мин Көн улы, күземдә Көн нуры бар.
Мин киләмен, мин киләмен, мин киләм—
Көннән туган, һуннан туган пәйгамбәр.

Сукыр чорны, күрмим димә, күзем, күр?!
Көнчыгыштан таң беленә инде, күр.
Таң да туа, мин дә туам—пәйгамбәр,
Көт син мине, «ләхәуләңне» укы бер?!

Көнчыгыштан таң беленә—мин киләм.
Күк күкрәде. Мин күкрәдем күк белән.
Җирнең йөзен караңгылык каплаган,
Җир йөзенә нур бирәмен. Көн бирәм.

Кап-кара төн. Хәсрәт тулы җир җыры,
Кап-кара төн. Иңрәп егълый төн улы.
Көнчыгышта ак алтын бер сызык бар:
Мин киләмен, мин—пәйгамбәр,—Көн улы.

## Хатын

Тәрҗемәче Флера Тарханова

Гаеп эш кылып Тәңрегә,
Каршы килеп әмеренә,
Куылды адәм оҗмахтан.
“Кайт, – дигән, — кара җиреңә,
Бишегеңә, гүреңә!»
Боерык килде шул хакта.



Батмас якты көне юк,
Фәрештәләр өне юк.
Тирә-юньдә тып-тыныч.
Үтмәслек биек тавы бар,
Исәпсез төрле явы бар –
Караңгы гүрдәй куркыныч.

Җиргә төште ялангач,
Җанда – хәсрәт, күздә – яшь.
“Ярлыка!”, – дип сорады.
Курыктымы җәзадан,
Алда күрәчәк казадан –
Зар булды, нык елады.

Җирдә ялгыз зарыгып,
Күктәге оҗмахын сагынып,

Елады үксеп, шешенеп.
Бер үк көндә яраткан,
Ут дәрья булып аккан
Ачты рәхмәт ишеген.

Оҗмахның йомшак җиленең,
Мәңге сулмас гөленең,
Хуш исләрен аңкытып,
Көмеш кәүсәр суыннан,
Суның алтын буыннан
Битендә нурлар балкытып,

Күкнең батмас көненнән,
Фәрештәләр өненнән,
Хур кызлары җырыннан,
Үз нурыннан нур бүлеп,
Хисси, назлы җан биреп,
Сөю, рәхмәт күленнән -

Ялатты Тәңре хатынны
Куылган адәм - колына,
Бассын диеп бер җирдә
Тугърылык, ышаныч юлына.
"Адашмассың, азмассың,
Туры юлдан язмассың –
Ир бул, – диеп, – соңыннан.

Оҗмахтан ерак киттем, дип,
Зур гөнаһка җиттем, дип,
Елама зар-зар, кайгырма!
Юлбаштан үрнәк алсаң,
Күңлеңне акка мансаң,
Оҗмах килер тагын да!»

Үтте заман. Яшь кипте.
Курку вә хәтер китте,
Онытты адәм Алласын.
Кузьяшькә ялган тулып,
Явызлык максат булып,
Җир йоттымы вәгъдәсен?



Кичәге хатын-фәрештә
Адәмне чөйде гарешкә.
Йөзе ак якты айдан, –
Елап туйгач, гәп сатып,
Иркендә уйнап ятып,
Булып калды бер хайван.

Йөзенең күптән күрке юк,
Күргәне хурлык, ирке юк.
Зардан тора бар өне –
Моны исеңә уймасаң,
Хатын бән өзми уйнасаң,
Озакка бармас ил-көнең!

## Гөлсемгә

Тәрҗемәче Флера Тарханова

Оҗмахтагы йомшак җилдән,
Мәңге балкып торган гөлдән
Яратылган хатын - сылу
Тормыш дигән бер тозакка,
Азга түгел, бик озакка
Килеп төште – эчте агу.
Хатын исмен Гөлсем диде,
Тормыш атын тылсым диде.



Оҗмахтагы кәүсәр судан,
Өстендәге алтын будан,
Фәрештәләрнең җырыннан,
Оҗмах суының шауыннан,
Яфраклар кыштырдавыннан,
Тәңренең нәкъ үз нурыннан
Яратылган фәрештәдер,
Туган иле – гарештәдер.

Алмаз канатлы фәрештә,
Ә иле аның – гарештә.
Җирне күреп канга баткан
Йөрәгенә хәнҗәр кереп,
Япан кырда ерткыч кебек

Үкереп һәм үксеп яткан
Илне жәлләп, җиргә төште,
Җиргә төште – гүргә төште.

Халкын жәлләп, җиргә төште,
Какты канат, өстән очты,
Кем кайгырса, шуны сөйде.
Көлгән белән бергә көлеп,
Үлгән белән бергә үлеп,
Көйгән белән бергә көйде.
Мохтаҗларга ярдәм итте,
Кайгы тулы диңгез кичте.



Учлап-учлап энҗе чәчте,
“Кил, – дип, – бире!” куенын ачты.
Тормыш - диңгез упкыны кук:
Диңгезгә кем атлап керер?
Керсә, аңа адәм керер,
Җанын сатып, җанын кыеп!
Тормыш – диңгез кычкырып көлде,
Сылу суга керде – үлде.

Үлде сылу – үтте еллар,
Үлде сылу – китте җырлар.
Бер ялгызы ал таң белән.
Канлы җиргә караш ташлап,
Күгеn уйлап кайгыра башлап,

Моңын күмеп хәсрәт белән
Оча һаман канат кагып,
Күзеннән кайнар яшь тамып.

Җан тибрәлер җыр эзеннән,
Ә нәфислек – нур эзеннән,
Хыял колы – мин бер акын.
Тормышта тар, тайгак юлга
Алып төшеп килә юрга
Көн кешесен кичкә якын.
Баткан көннең таңын күрдем,
Шул сылуның җанын күрдем.

Кояш кызының җан җырын,
Йөзендәге якты нурын
Эзләп йөреп әлсерәдем.
Йөрәгемне, кулым биреп,
Кан аралаш яшем түгеп:
«Юлым – сиңа, килче!» – дидем.
Кайрылып та карамады,
Җан-йөрәгем яралады.

"Мин – үлгән бер җанмын, – диде,
Фәрештәләр күмгән инде».
Керфек какты – китеп барды.
Йөзендәге балкыш нуры,
Аузындагы моңлы җыры

Гомрем буе шунча дулап ни кылдым?

“Җил бул!” – дидең, җил булып исмәдемме?
Вакыт сайлап, «иртә» йә «соң» дидемме?
Җилдәй шашып, кискен искән җил белән
Дөрләп янган утларга төшмәдемме?

“Ут бул!” – дидең, ут булып янмадыммы?
Ни дә булса көйдерми сакладыммы?
Көлне дә алдым кочакка, гөлне дә,
Монсы «көл», ә бусы «гөл» дип сайладыммы?



“Су бул!” – дидең, челтерәп акмадыммы?
Йөз уралып, еландай ятмадыммы?
Ирке чикләнгән судан татар җанын
Челтерәүбән сихерләп тапмадыммы?

“Кояш бул!” – дидең, Кояштай көлмәдемме?
Вакытны көндез йә төнгә бүлдемме?
Кояш – кайнар: күпләр янды кочакта,
Бу гамәлдә көнлекче мин дидемме?

“Ай бул!” – дидең, Ай булып йөзмәдемме?
Әфсен укып, Җир йөзен гизмәдемме?
Гаҗәп якты тылсымлы нурлар сибеп,
Бик күпләрнең үзәген өзмәдемме?

Син «Сөй!» – дидең, купләрне сөймәдемме?
Күбәләк булып утта көймәдемме?
Үлгәннән соң җан керү булмаса да,
Мин байтак күлмәк-кәфен кимәдемме?

“Җыла!” – дидең, шактый яшь түкмәдемме?
Дәрья булды күз яшем – күп дидемме?
Яшем бетсә, кып-кызыл кан җыладым,
Җыламыймын, күздә яшь юк, дидемме?

«Ата-анаңнан биз!» – дидең, бизмәдемме?
Ялгыз калып, каңгырып йөрмәдемме?
Башкаема байтак кара көн төште –
Газиз ата-анамны эзләдемме?

“Илең ташлап кит!” – дидең, китмәдемме?
Җир читендә йөреп, бу чит дидемме?
Бәгыренә еландай кереп ятып,
Теләмәсәм дә, якын итмәдемме?

«Байлыктан кач!» – дидең син, качмадыммы?
Куйнымны яхшылыкка ачмадыммы?
“Нәҗескә – дуңгыз, ә сөяккә – ит” диеп,
Бар малны суга салып, шашмадыммы?

“Юкны эзләп тап!” – дидең, тапмадыммы?
“Инде Айга чап!” – дидең, чапмадыммы?

Ни кирәк тагын? Бар боерык үтәлде –
Чорсыз йөрәк, хезмәтне акладыңмы?

Акламадың, алдадың – төгәл беләм,
Тагы бер ай – егерме җидегә керәм.
Утыз, кырык... Картаям, сүнәм, үләм...
Исәп иткәндә, илемә ни бирәм?!

Янә бер ай – егерме җиде яшь була,
Утыз... Кырык... Саргаеп йөзем сула.
Ел артыннан җилдереп еллар туа,
Көн-төн саен җаныма сагыш тула.



Тынгысыз йөрәк асманга үрләде,
Исәр йөрәк акылга юл бирмәде.
Яшьлек ул – айнытмас бер агудыр:
Нык көнләшеп, мәхәббәтне җирләде.

Акылы кимгә әйләндем, кур, көнем,
Бер көн килеп, үзенә алыр үлем.
Кара җирне кочаклап мин ятармын,
Шул чак мине ничек бәяләр илем?

“Җил иде, җилдәй җилеп үтте!” – дипме?
“Баш югалтып утка ташланды!» – дипме?
Ду килеп янган утны Тәңре күреп,
“Тончыгып ят, исәрем”, дияр көлеп.
“Йә булмаса: «Гөл иде – сулды!» – дипме?

«Бар булганын ул Айга сонды!» – дипме?
“Айга чапкан хәлсез бер арыслан кук
Юлында үзе корбан булды», – дипме?

«Кояш иде, гомере буе көлде!» – дипме?
«Кояш иде, тик сөймичә сулды!» – дипме?
“Кояш иде, шул Кояштай көлә белде,
Көлә-көлә егылып та үлде!» – дипме?

“Гүзәллекне күккә чөйгән җырчы!” – дипме?
«Йөрәк серләрен чишәрлек серче!» – дипме?
“Йә куаныч, яки кайгы баскан көндә
Яныма килеп, әй, Акын, торчы!» – дипме?



Әллә инде яныма да бармас микән?
Исемемне теленә дә алмас микән?
Япан кырда караеплар ялгыз торган
Каберемә күзен дә һич салмас микән?

Дарига, ул көнләшкән көнем кара,
Казакъ иле, бер ауыз сүзем сиңа:
Тәнкыйтьлим дисәң, гаделрәк бул әле,
– Кинәңне йөрәккә әйт, койма миңа...

Әйтмә, зинһар, йөрәге шашкан, диеп,
Теләгәне гамәлгә ашкан, диеп.
Сөеп, көлеп, көеп, күз яшен түгеп,
Шашкын йөрәк үлде дә тынды, диеп...

## Туган җир

Тәрҗемәче Флера Тарханова

Бу дөньяга аяк баскан туган җир,
Кендек кискәч, канны синдә юган җир.
Ястык – алтын, кире кайтмас көнемдә
Уен уйнап, чебен-черки куган җир.

Яратылдым туфрагыңнан, син – төбем,
Һич ялгансыз, бары синнән җан-тәнем.
Бүтән җирдә миңа моңсу, караңгы,
Бар дөньям – Чулпан, Аем һәм син – Көнем.



Татлы суың тәме аузымнан китмәс,
Куе урман, кыр, суыңа җир җитмәс.
Киң далаңда мин уйнап калсам әгәр,
Ялгышырмын, кешелеккә ир җитмәс!..

Балак төреп, бәти куып, ярышып,
Көч сынаштык, үзара бил алыштык.
Төн – аксөяк, алтыбакан, ә көндез,
Өйрәтәм дип, асау тайга ябыштык.

«Адәм улы – Алла колы» дигән рас,
Ничек куса, шулай киттек – юк ашым.
Кем уйлаган, мин дә читкә китәр дип,
Туган җирем, сине ташлап яшь башым.

## Алданган сылу

Тәрҗемәче Флера Тарханова

Күреп туймас тулган ай йөзең иде,
Сихри-серле кап-кара күзең иде.
Ак майдай, мамык кардай керсез тәнең,
Әйтерсең, бакчадагы йөзем иде.

Җил тими, янып торган көнең иде,
Җанга шифадай яткан сүзең иде.
Үтеп киткән Пәйгамбәр эзләредәй,
Чук аягыңнан төшкән эзең иде.

Бүген ул сыйфатларның берсе дә юк,
Аягыңа ялның тиясе дә юк.
Никтер гел шәраб, ястык исең алды,
Аһ ордың: тышың – ялкын, эчеңдә – шок

Теленә шул төлкенең тиз алдандың,
Уйламый таңны, һәр төн ләззәт алдың.
Саф исмең, күркәм йөзең бик тиз китеп,
Гомер бакый котылалмас утта калдың.

Таралды мир аузына яман атың,
"Бозылган!" – диде инде якын, ятың
Ысылдап ул да, бу да шуны әйтер –
Яшь түгелеп, шулчак бетәр тәкатең.

## Саргайдым

Тәрҗемәче Флера Тарханова

Саргайдым, көннән көнгә куәт кимеп,
Йөрәгемне кара елан суырып имеп,
Акрынлап сүнеп барам янган шәмдәй,
Мөлдер-мөлдер кайнар яшем түгеп.

Бигрәкләр дә авыр булды көн уткәзү,
Агу йотып, айдан озын төн уткәзү!
Уйлап, сөйләп һәм шаярып йөрер чакта,
Үлем көтеп, яшь гомремә чик уткәрү.



Еш – еш ник тибәсең, йөрәк, нинди сәбәп?
Еш тибүең ут тәнемне сихәтләрме?
Тамырдагы тәнем юган сары суны,
Пакъләндереп, чип-чиста саф кан итәрме?

Күзнең нуры калмады: төнгә бәйләнде,
Караны – ак, акны кара дип алдандым.
Алмадай пешеп торган ике битем,
Куырылып, каны качып, көлгә әйләнде.

Бөтен тәнгә шул агудан бер чир йокты –
Инде менә ике айлап ялкын йоттым.
Көндез - Кояш, төнен көмеш Айны күрмим,
Җаным гел азат булса да, тәнем – тоткын.

Йөримен лә һәр көн саен газап асып,
Үлем килә, мәгарәдәй куенын ачып,
“Кыйнауга озаклап түзсен бу!” – дигәндәй,
Мыскыл итеп, адымнарын санап басып.

Әй син, Җәллад! Тиз алучы әҗәл дә бар:
Кыйнама, тизрәк үлимче – угыңа ал.
Сызып тәнем, кычкырыплар җан бирәем,
Ялкыны күкләргә ашкан утларга сал!

## Анама

Тәрҗемәче Флера

Гомеремнең кап-караңгы төнендә,
(Һични белмим: төшемме бу, өнемме?).
Уңны – сулдан, утны судан аермас,
Көчсез, хәлсез, исемем белмәс көнемдә –

Кочагыңа алып сөйдең син, Анам,
Рәнҗүең юк, бөтен сүзең: «Җан балам!»
Эссе-суык, җил яңгырлар тигезми
Асрап, саклап, түбәм булдың, и Анам.

Төндә торып, төн йокыңны дүрт бүлдең,
Мин тыныч йокласын дип, аз сөйләдең, аз көлдең.
Ыңгырашсам йә ачыксам, йә туңсам,
Ни хикмәттер, шул мизгелдә үк белдең.

“Җаным, – дидең, – күз карасы әмирем”,
Сөйдең, кочтың, дидең: «Татлы бәгырем».
Тәпи бассам һәм елмайсам, егылсам,
Еласам да һәрчак булдым кадерлең.

Җаным Анам – йомшак телле, ак күңел,
Үтәр юлым тигез түгел, һаман үр,
Адашып калып, кичәр булсам озын юл,
Чит җирләрдә яман юлдан сакларга
Җан балаңа ак теләкләр тели күр.

## Сөйгәнемә

Тәрҗемәче Флера Тарханова

Берөзлексез сине уйлап яндым-көйдем,
Синнән башка һичбер җанга күңел бармый.
Шунысы авыр: син бер сүздә ялган белән,
Сине эзлим, ялганыңнан арыналмый.

Кайгы йоттым: «аһ» дип әйтсәм, чыкты ялкын,
Тәнем сау да, тик эчемдә көчле янгын.
Көйдергән шул көчле янгын тәэсирендә
Бәхетсез, хәлсез җаныма иңә шаукым.

Сүзем, күзем әйтеп тора сөйгәнемне,
Нурлы йөзләрем саргаеп көйгәнемне.
Талган йөрәк, йөдәгән һәм сулган тәнем
Раслый минем гел кол булып йөргәнемне.

Көне-төне сине эзләп хәсрәт җыйдым,
"Утка төшкән Мәгъшугыңны сөйче", – дидем.
Түгелгән күз яшьләремә исең китми,
Тәнеңне ятка салдың да көнче иттең.

Җан ордым, җаннан телдем – кайрылмадың,
"Кит әле!" дигәнеңнән айрылмадың.
Күз алларыңда дөрләп уттай яндым –
Жәлләп, хәтта сүз белән кайгырмадың.

Күңелемә кергән иде синнән балкыш –
Килде шуны сихәт итеп гел тоясым.
Булды - җитте! Мин китәмен сине ташлап,
Хуш инде, мине көл иткән ут кояшым.

«Син сөймәгәч, таптым инде үземә яр,
Кирәгең юк, миһербансыз, юлыңнан бар.
Миңа хәзер ул яр белән тыныч, рәхәт
Һәм барыбер — язын, кышын яуса да кар.

Беркайчан да беркем ташлап китмәс инде,
Синең кебек кайгылы да итмәс инде.
Үзгәрмәс бер калыпта да бу тормышым,
Шатлык белән гайбәтләр дә көтмәс инде.

Хуш, күз нурым! Бәхетсез бер Мәгъшугың күр.
Саубуллашыйк, мин китәем, кулыңны бир.
Алдымда – колач җәеп каршы алучы
Миһербанлы сөйгән ярым – ул кара җир!

## Сөй, җан сәүләм

Тәрҗемәче Рәдиф Гаташ

Сөй, җан сәүләм, тагын да сөй, тагы да... –
Җылы, татлы агу тарат каныма.
Бу ләззәтнең минутын да бирмимен
Патша тәхете, бөтен дөнья малына.

Кочаклат та нәзек талдай билеңнән,
Сөйдер, сәүләм, татлы балдай телеңнән:
Рәхәт тетрәп, истән язсын йөрәгем,
Тәнем утта, эреп барам дәмеңнән,

Кер куйныма, нечкә бил, боргаланып,
Тарат чәчең – ефәк ятсын уралып.
Җаным! Җаным! Тизрәк тисен түшкә түш,
Күз йомылган – еш-еш сулап, сут алып...

Чәчең – төндәй, тәнең – ап-ак, йөзең – Ай,
Тешең – энҗе, күзең, сәүләм – коралай.
Ләззәт, рәхәт, бәхет – барсы куйнында,
Сорамыймын күктән – оҗмах шул бугай:

Сөй, җан сәүләм, тагын да сөй, тагын да!
Җылы, татлы агу тарат каныма.
Яраткан Тәңремә тик бер теләгем:
Үтмәсен бу төн... атмасын таңы да!

# Терелдем

Тәрҗемәче Рәдиф Гата

Сансыз көннәр – уйга күмелгән идем,
Берни күрми – күңелен тапмый күңелнең.
Күзем – яшьле, үзем – уйдан тузган бер
Үлек идем, бүген тагын терелдем.

Җаным үлгән иде, җанга җан керде,
Тамыр кипкәндә, эссе кан йөгерде.
Кургаш сыман болытлы җан күгемнең
Бүген тагын бәхет таңы беленде.



Бүген – гомеремнән оҗмахка юл булды,
Бүген – минем кочагымда Ул булды!
Аны кочтым, шәраб эчтем, шат идем:
Бүген минем кочагымда Гөл булды.

Бүген минем кочагымда кем булды?
Бүген минем кочагымда Гөл булды.
Бүгенге төн миңа алтын көн иде,
Минем кочагымда Кояш – Көн булды!

Үзем генә беләм, нинди җан кочтым,
Җир кочмадым, түгел тузан – таң кочтым,
Җаным юып, йөрәгемне яңартып,
Бүгенге көн тән кочмадым, җан кочтым
Бүгенге көн тән кочмадым, җан кочтым,

Җан кочтым мин, таң кочтым – күккә очтым,
"Сөям" диде бута күзе, мөлдерәп,
Яшен түкте – яшен эчтем, бал эчтем.

"Күккә омтылам, чишче, дөнья, аягым!
Хөр булса аяк, алып Муса таягын,
Китәр идем Тәңрем эзләп, Турны эзләп,
Җан ярым, дип, Сарыарканың саягын", –

Диде алма иреннәре, дерелдәп,
Бута күзендә кайнар яшь мөлдерәп.
Җыелган яшь бер түгелми буламы? –
Түгелде дә ... җан теленде, ут көйрәп...



Үкси-үкси: "Сөям, син дә сөй!" – диде,
"Гомер буе көям, син дә көй!" – диде.
"Синең белән җаным бергә, җан ярым,
Син дә җан сөй ... тиле канны тый!" – диде.

Ул елады, мин дә бергә еладым,
Үкси-үкси: "Сөй генә!" – дип сорадым.
Күп еладым, шул гөнаһсыз яшь аша
Алда күрдем гомер юлын, морадым...

... Егерме җиде ел! – йөрәкнең колы идем,
Төнен түгел, көнен белеп гомернең.
Ике тамчы яшьтә юып җанымны,
Үлгән җирдән бүген мәңге терелдем.

## Аерылганда
## (Г...гә)

Тәрҗемәче Рәдиф Гата_



Сөеп сине, бер ел агулаганмын:
Бәгъреңә алдың ... нигә мине кумадың?
Һушсыз калдым: аерыласын белеп, мин
Канлы яшьтә күзне нигә юмадым?!

Сөйдең мине: башка җанны күрмәдең,
Яшең түктең – кадреңне ник белмәдем?!
Мөлдерәгән шул чын гәүһәр яшеңнең
Сәдакасы булып, нигә үлмәдем?!

Белдем, бүген мине ташлап, китәсең,
Көмеш сулы Иделеңнән үтәрсең...
Бута күзлем, үтереп кит кулыңнан,
Тере килеш ничек ташлап китәсең?!

"Күрешкәнче... Хуш!" дип, йә, бир кулыңны!
Калтырыйсың үз кулым, әйт, ни булды?!
Яза алмыйм, Гөлем, хәлем калмады:
Күземдә – яшь, йөрәктә – агу тулы...

## ... гә

Тәрҗемәче Рәдиф Гаташ



Алтын көннәр куандырмый,
Ефәк гөлләрең юатмый... –
　　Җиттең дә тиз үттең, Яз!
Агач, үләннәр саргайган,
Якты күлләр корып калган –
　　Каңгылдап кайда кунар Каз?!

... Өн катыш төштәй, пәризат,
Күрендең дә, булдың ник ят? –
　　Яндырдың тик җанымны...
Караган күктән хур идең,
Күбрәк күреп калыйм, дидем... –
　　Күккә ишек ябылды!

## Урал

Тәрҗемәче Рәдиф Гаташ

Озын Урал – Көн һәм Төн чигарасы:
Бер якта – көн, бер якта – төн баласы.
Аргы ягы – күк күзле җен оясы,
Бирге ягы – Төркнең сардаласы.

Урал – ул чал Алып, гел сакта торган:
Көн һәм Төн чиге – дивар, Кытай корган.
Алып тәне – таш, мыегы – куе урман, –
Багып уң, сул... төшлеккә, мыек борган.

...Карамыйча һичнигә күзем туктап,
Алыбым эзләп килгәндә, тансыклап,
“Йокы – дошман” сүзе хактыр: төнен мин
Чал Алыпны күрми узганмын, йоклап...

Кичер, Алып! Йөзеңне күрә алмадым,
Иелеп сиңа сәлам дә бирә алмадым.
Гамәл кылып – даламнан илче булып,
Сакчы бабам Алыпка килә алмадым.

... Озын Урал – Көн, Төннең чигарасы,
Үлем – Төндер... Гомер – гөл, һун даласы,
Гомер белән үлем чиге арасын да
Йоклап узса әзәлдән җир баласы?!

Ике дөнья: Көн һәм Төн... Гомер – Үлем...
Берсе – бишегең... Ә берсе – әзер гүрең.
... Бала булып ята бер бишегеңдә
Сары дала иркәсе – казакъ илем!

## Җир йөзен туфан басса икән

Тәрҗемәче Рәдиф Гаташ

Җир йөзен туфан басса икән! –
Тик таулардан ашса икән!
Таудай дулкын котырынып,
Олы күбек ташса икән! –

Басса икән туфан җир йөзен!
Басса икән күбек көн күзен!
Җанлы, җансыз юк булып,
Калсам икән ялгыз бер үзем.

Җан иясе тончыкса,
Өн иясеннән өн чыкса... –
Караңгы җирнең күгенә
Кояш булып шунда мин чыксам! –

Менә нинди уен уйнар идем:
Ялкында барсын ялар идем.
Иксез-чиксез дөньяда мин
Ялгыз калып, янар идем...

Дөрләгән ут – ул ялгыз җан,
Җир сыйфатлы адәм калмаган:
Дөрләп торган утымнан
Яратыр идем яңа Адәм!

## Казакъ теле

Тәрҗемәче Рәдиф Гаташ



Көч кимепме, борынгы изге ту ауды?
Кеше батыр – куркак, сөймиме яуны?
Ирекка әйдәгән көчле җан очып,
Каны суынган, йөрәге сулганмы?

Кыран-кошның куш канаты кыркылды...
Кояш булып балкый алган Ил тынды.
Мәгърур Алтай – алтын Ана истә юк,
Ханнар, батырлар – зур җаннар онытылды...

Ил сөяр ир, хөрлек, гайрәттәнме ардың –
Явыз тәкъдир оныттырдымы барын?!
Кояш-көннең мирас алтыны булып,
Сүнмәс йолдыз – бабам теле, син калдың!

Якты төшми яткан мәгъдәнсең, телем!
Таза, тирән, үткен, көчле, киң телем!
Таралышкан Түрк нәслен бәгъреңә
Ак кул белән җыя алырсың Син, телем!

## Тәңрегә үпкә

Тәрҗемәче Рәдиф Гаташ

Олуг Тәңре, көч-кодрәтең зур, беләбез,
Гадел, диеп, һәр эшеңә без күнгәнбез.
Үз колларын аяр Иябез дип, сиңа
Үзебез үк ирек тезгенен биргәнбез.

Авыздан "Алла!" атың ташламыйбыз,
"Алла"сыз һичбер эшкә башламыйбыз.
"Гадел ханыбыз, буйсындык боерыгыңа", дип,
Боерыксыз бер адым да атламыйбыз.



Кичә күр, Тәңрем: бу сүз – бәндәчелек,
Әмма безгә золымың – ник? Юк гаделлек:
Рәхимеңнән шул кадәр дә буш калганбыз, –
